МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

14.01.2016 № 15

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2016 елның 11 февралендә теркәлде, № 3196

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү
һәм социаль яклау министрлыгының
аерым боерыкларын көчләрен югалткан дип тану турында

2015 елның 31 гыйнварында Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәте арасындагы Россия Федерациясенең инвалидларга һәм ветераннар исәбенә керүче гражданнарның аерым категорияләренә социаль ярдәм чараларын бирү буенча, шулай ук дәүләтнең шифаханә-курортта дәвалануга юлламалар (медицина ягыннан күрсәтмәләр булганда) һәм дәвалану урынына шәһәрара транспортта түләүсез бару һәм кире кайту мөмкинлеге бирү буенча социаль хезмәтләр күрсәтү рәвешендәге социаль ярдәмен күрсәтү буенча вәкаләтләренең бер өлешен башкаруны Татарстан Республикасы Хөкүмәтенә тапшыру турында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 27 декабрендәге № 2417-р әмере белән расланган килешүнең гамәлдә булу вакыты бетүгә бәйле рәвештә **боерык бирәм:**

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының түбәндәге боерыкларын көчләрен югалткан дип танырга:

“Техник тернәкләндерү чаралары белән тәэмин итү өчен – инвалидларны һәм протезлар (теш протезларыннан гайре), протез-ортопедия эшләнмәләре белән тәэмин итү өчен, ветеран булып саналучы гражданнарның аерым категорияләрен

исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында” 02.03.2015, № 121;

“Инвалид үзе сатып алган техник тернәкләндерү чарасы һәм (яки) ишарәле рус телен тәрҗемә итү (сурдотәрҗемә, тифлосурдотәрҗемә) буенча түләнгән хезмәтләр өчен компенсация түләве, инвалидның юл күрсәтүче этне асраугa һәм аңа ветеринария хезмәтләре күрсәтелүгә чыгымнарына ел саен бирелә торган акчалата компенсация түләве билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында” 22.04.2015, № 252;

“Социаль хезмәтләр җыелмасы рәвешендә дәүләт социаль ярдәмен алу хокукына ия гражданнарны, медицина ягыннан ихтыяҗ булганда, төп чирләрне булдырмый калу максатыннан, шифаханә-курортта дәвалануга юлламалар белән тәэмин итү өчен исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында” 18.06.2015, № 421.

**Министр** **Э.Ә.Зарипова**